**МИНИСТЕРСТВО**
**ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**УРМАН ХУҖАЛЫГЫ**
**МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

30.09.2024 № 375-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 26 декабрендәге 610-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 26 декабрендәге 610-осн номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.К.Гомәровка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы министрлыгының
2024 елның ____________ №_____
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 26 декабрендәге 610-осн номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

2 пунктта:

2.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гражданинның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аларның түләү йөкләмәсен үтәүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә;»;

2.3 пунктчаны көчен югалткан дип танырга;

2.5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки Министрлык бюджетка түләүләр буенча әҗәтләрне түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы үтүгә бәйле рәвештә дә;»;

2.6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгару (бөлгенлек) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булса;»;

түбәндәге эчтәлекле $2.6^1$ пунктчаны өстәргә:

«$2.6^1$. Бюджетка түләүләр түләүче затны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты кабул итү;».

4 пунктның 4.3 подпунктында:

дүртенче абзацта «2.3 пунктчасында» сүзләрен «2.2 пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «2.6 пунктчасында» сүзләрен «2.6, $2.6^1$ пунктчаларында» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «2.6 пунктчасының өченче абзацында» сүзләрен «$2.6^1$ пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга.